«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге»муниципаль берәмлеге Советы карары

14.06.2017ел. № 56

Муниципаль районның аерым мәсьәләләрен хәл итү буенча вәкаләтләрне тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советына Кече Салтык авыл җирлеге башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләр тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә: җирлекнең генераль планнарын, җирлектән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау, җирлекнең генераль планнары нигезендә әзерләнгән территорияне планлаштыру буенча документацияне раслау, җирлекләрнең шәһәр төзелеше проектлауның җирле нормативларын раслау.

2. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдимне кабул иткән очракта, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге башкарма комитетына әлеге вәкаләтләрне әлеге карарның 1 пунктында тапшыру турында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Әлеге карарны түбәндәге мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә: - ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманче урамы, 9, мәдәният йорты бинасы;-ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9, авыл китапханәсе, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге бүлегендә урнаштыру юлы белән.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Кече Салтык
авыл җирлеге башлыгы,
Татарстан Республикасы Кама Тамагы
муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге
Советы рәисе А.Г.Җиһаншин